*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

Сигезенче сан

Апрель, 2015 нче ел

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Кошларны каршылау

Безнең илдә “Кошлар көне” 1940 нчы еллардан бирле үткәрелә икән. Кошлар килүен каршылап, гимназия укучылары, Җиңү язын каршылап, 70 данә сыерчык оясы ясап куйдылар. “Иң матур оя”, “Технологик яктан иң дөрес ясалган оя”, “Иң оригиналь оя” номинацияләрендә җиңүчеләр билгеләнде.

Рәхим итегез, кошкайлар! Туган җирегездә сезне хөрмәт белән көтәләр!

### “Җиңү өчен бабама рәхмәт” акциясе

Гимназия укучылары, Бөек Җиңүнең 70 еллыгын каршылап, төрле чараларда актив катнашалар. Ай дәвамында “Җиңү өчен бабама рәхмәт” акциясе кысаларында укучыларыбыз һәм укытучыларыбыз аерым билгеләр тагып йөрделәр. Гимназиядә ветераннар белән очрашулар, аларның гаиләләренә шефлык хәрәкәте, сугыш турында истәлекләрне барлау юнәлешендә эшләр дәвам итә.

### Бәрәкәтле каникуллар

Каникулларда гимназиядә балалар тавышы тынып тормады: түгәрәкләр эше, консультацияләр уку вакытындагыча үткәрелде.

II россиякүләм “Фоат Садриев укулары” узды. Гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы Мөхәмәтова Лениза 1 нче урын, 8а, 9б сыйныфы укучылары башкарган “Талантлы якташларыма күңелемдә һәйкәл куям” проекты 1 нче урын яуладылар.

9 нчы һәм 11 нче сыйныф укучылары өчен математика, рус теле, татар теле һәм сайлап алган предметлар буенча имтиханнар биреп, үз белемнәрен сынап карарга мөмкинлек булдырылды.

### Мөслим хәбәрләре

1 апрельдән сынау рәвешендә генә Мөслим эчендә маршрут автобуслары җибәрү күздә тотыла. Пассажирлар күләме исәпкә алыначак, көн дәвамында йөрүчеләр күп булса, маршрут автобусларын арттырачаклар. Хөрмәтле укучылар, әйдәгез, акциягә без дә кушылыйк! 1 апрель көнне барыбыз да көн буе автобусларда йөрик!

### Ыкта боз китте

Бүген иртән Ыкта боз китте. 8 нче а сыйныфы укучылары беренче-икенче дәрес вакытында боз китүне күзәттеләр.







### *Соңгы казанышлар*




*Гимназия директоры Азат Мирзаянов ЮНЕСКО премиясенә лаек булды. Котлыйбыз!*




*Гимназиянең “Голос” проектында җиңүче - Алмаз Вәлиев. Котлыйбыз!*




*Апрель-май айлары - чисталык икеайлыгы. Сәвия Закирҗановна бу уңайдан махсус приз булдырды. Май аенда йомгак ясалачак. Медаль иясе булырга ашыгыгыз!*

# 1 НЧЕ АПРЕЛЬ - КӨЛКЕ КӨНЕ

## Кызыклы сәхифә



*Кечкенә чакта кем генә космонавт булырга хыялланмаган! Ә син хыялланасыңмы? Беләм, беләм, синең дә очып караганың бар. Берәү баскычтан оча, икенчесе – тәрәзәдән, коймa башыннан турыга гына очып гимназиягә килеп керүчеләр дә бар... Мәхәббәттән очканнар да очрый... Күрәсез, очу төрлечә була. Ф. дә очып караган бит әнә. “Я летаю, я в раю”, - дип җырлады микән очканда?*

*Хәзерге вакытта космонавт булырга хыялланучылар өчен әзерләнергә шартлар җитәрлек. Бигрәк тә гимназиядә. Ышанмыйсызмы? Безнең директорның элементләре белән мөмкин булмаганнарны булдырырга була! Күптән түгел бездә С.З.Хабирова чакыруы буенча, Мәскәү космонавтлар әзерләү үзәгенең Казандагы филиалыннан вәкил В.Р.Летягов булып китте. Ике арада килешү төзелде. Ике ай түләүсез курсларда шөгыльләнгәннән соң, иң яхшы күрсәткечләргә ирешкән егетләр һәм кызлар 01-АПР-15 маркалы яңа төр космик корабльдә Марс планетасына юл тотачак. Космик киңлекләргә очарга теләүчеләргә бары тик өч документ: ЛР-01-04 формасында дәресләрдән киту өчен рөхсәт кәгазе, СХ-2015 формасында физикадан еллык билгеләр күчермәсе, паспорт копиясе кирәк. Гариза белән гимназия директоры А.Ф.Мирзаяновка мөрәҗәгать итәргә.*

*PS: Шөгыльләнү өчен 200 кабинет җиһазлана. Төшегезгә дә кермәгән җиһазларның бер өлеше кайтты инде.* ***Яшерен мәгълүматларны Камилә Ханеева җыйды.***

## МӘЗӘКХАНӘ

### Булган хәл

Класска директор керә һәм Хәсәновка:

- Динар, бар әле, 3 нче этаждагы тәрәзәләрне буя, зинһар өчен, – ди.

Динар ярты сәгатьтән килә:

- Азат Фәритович, мин тәрәзәләрне буядым, рамнарын да буйыйммы?

### Татар теле дәресендә булган хәл

Эльмира Василовна сорау бирә:

- Камилә, “ак” сүзе нинди сүз төркеменә карый?

Камилә бер дә икеләнмичә җавап бирә:

- Төс.

### Булырга мөмкин хәл

Чебурашка кибеткә керә һәм сатучыдан:

- Бер тамчы сок күпме тора? – дип сорый.
- Бушка.
- Алайса, бер шешә итеп тамызыгыз әле.

### Автомәктәптә булган хәл

Автомәктәптә Радик Ахунов Сәхипгәрәевадан имтихан ала.

- Двигатель ничек эшли?
- Үз сүзләрем белән мөмкинме?
- Әлбәттә!
- Вжжжж! Вжжжж! Вжжжж!



### Кайгы уртаклашу

Гимназия үзидарәсе, Шәрифуллин Заһирның ручкасы югалу сәбәпле, аның авыр кайгысын уртаклаша.

### Алыштырам

Гимназиядә “2” ле билгесенә укучыны теләсә кайсы мәктәпнең “3” легә укучысына. Сатулашырга була.

Гимназия директоры

### Сатыла

Гимназия буфетына яңа җайланма кайтарылды. “Шоколад фонтаны” на 1 нче апрель көнне 12.00 дә презентация. Дегустациягә ашыгыгыз!



### Табылдыклар өстәле

Бассейн керү комплекты табылды. Гимназия вахтасына паспортларыгыз белән мөрәҗәгать итүегез сорала.

ТЫЛСЫМ+

Апрель, 2015 нче ел

*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Мөхәммәтханова Айгөл
**Корреспондентлар:** Әһлиуллина Язилә, Ханеева Камилә
**Дизайнер:** Хәбибуллин Руслан

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Ринат Сафиуллин
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym